| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 март 2023 ел № 175

**Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2014 елның 22 октябрендәге «Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәне раслау хакында» 250 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль законына туры китетреп, Балтач район прокуратурасының 2023 елның 21 февралендәге 02-08-01/Прдп45-23-20920011номерлы протестын карап һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2014 елның 22 октябрендәге 250 номерлы карары (2015 елның 17 апрелендәге 273 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге 287 номерлы) белән расланган Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 6 пунктның в пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр, әгәр килешүләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артык булса, ул, аның хатыны (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балалары тарафыннан мәгълүмат тапшыру елына кадәр календарь ел дәвамында төзелгән җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып

алу буенча һәр килешү буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм бу килешүләр нигезендә акча алу чыганаклары турында мәгълүмат бирү.»

- 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тапшырылган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча килешү төзү өчен акчалар алу чыганаклары турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнарны белән билгеләнгән шәхси мәгълүматны яклау таләпләрен үтәп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин